КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

2019 ел, 30 апрель г.Казань № 372

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 ноябрь, 936 нчы; 2013 ел, 10 июнь, 395 нче; 2013 ел, 2 ноябрь, 836 нчы; 2016 ел, 19 апрель, 239 нчы; 2017 ел, 28 июнь, 447 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урынны махсуслаштырылган торак фондына һәм махсуслаштырылган торак урыннар наймының типлаштырылган килешүләренә кертү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары нигезендә эшләнгән.»;

6.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар категориясенә караган затлар исемлегенә кертелгән һәм 23 яшькә җиткән, аларның язма рәвештә гризалары бенча 18 яшькә җиткәннән соң торак урыннары белән тәэмин ителергә тиеш, шулай ук балигъ булмаган вакытка тулысынча эшкә сәләтле булган очракта тәэмин ителергә тиеш.»;

6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4 Торак урыннары ятим балаларга торак йортлар, тиешле торак пункты шартларына карата уңайлыклары булган фатирлар, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормалары буенча бирелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин